**Березняк авылы Х. В. Ваһапов исемендәге төп гомуми белем бирү мәктәбенең тарихы битләреннән....**

Мәктәп - туган җир җылысын бирүче, балачак һәм үсмер еллар истәлеген саклаучы, еллар дәвамында үзенә чакырып, олылап каршы алучы изге йорт ул. Үз мәктәбенең тарихын белмәгән авылның киләчәге өметсез. Авыл мәктәбе ул -тел сакчысы, милләт сакчысы, буыннар бәйләнешен булдыручы. Һәр кеше яшәеш чорына нинди дә булса нәтиҗә ясарга тиеш. Киләчәк буын өчен авыл, мәктәп тарихын өйрәнүгә материал туплау бик мөһим. Республикабызда мәктәпләр бик күп. Аларның һәркайсының үз тарихы, үз язмышы. Березняк төп гомуми белем бирү мәктәбенең башлангычы, чишмә башы кайда икән?

2006 – 2007 нче уку елында мәктәбебез тарихына багышланган музей почмагы эшләнде.

Музей почмагының төп максаты: авылыбызда мәгарифнең үсеше, аны үстерүгә үзләренең өлешләрен керткән һәм мәктәп тарихында эз калдырган шәхесләр турында документлар җыю, ирешкән уңышлар турында нәтиҗәләрне барлау, яңалары белән тулыландыру.

Билгеләнгән максатларны тормышка ашыру өчен түбәндәге бурычлар куелды: үз тарихыңа кызыксыну уяту, битараф булмаска өйрәтү, мәктәп тарихын торгызу һәм шуңа бәйле рәвештә музей почмагын тулыландыру.

Березняк авылы Х. В.Ваһапов исемендәге төп гомуми белем бирү мәктәбенең тарихына багышланган музей почмагы түбәндәге дүрт бүлектән тора :

**<u>Мәгарифнең чишмә башы</u>**

1904 нче елда Березняк авылында беренче мәдрәсә ачыла. Анда алдынгы карашлы Минһаҗев Гаян мулла балаларга белем бирә башлый. Мәдрәсәдә 15-20 шәкерт белем ала. Укыту гарәп телендә алып барыла.Авылда фән нигезләрен укыту өчен беренче тапкыр дәүләт тарафыннан 1917 нчы елның көзендә мәктәп ачыла. 1917-1926 нчы елларда авылда башлангыч мәктәптә Әюпов Давыт Әюп улы эшли.1926-1929 нчы елларда мәктәптә укыту һәм тәрбия эшен Ягудин Нәҗип Яхүд улы алып бара.



1937 нче елга кадәр авылда башлангыч мәктәп кенә була. 1938 нче елда мәктәп җидееллыкка үзгәртелә. Манарасы киселгән мәчеттән ике катлы итеп үзгәртелгән бинага урнашкан җидееллык мәктәп белән Шиһабетдинов Миннегали Ибраһим улы җитәкчелек итә.

1941 елда Бөек Ватан сугышы башлана. Кадрлар җитмәү сәбәпле, 1944 нче елда башлангыч мәктәп итеп калдырыла. 1944-49 елларда Билалова Маһиәнвәр Билал кызы белем бирә.

1949 нчы ел. Мәктәп кабаттан җидееллык итеп үзгәртелә. Директор итеп Ваһапов Харис Ваһап улы билгеләнә. Харис Ваһапович мәктәп белән 37 ел җитәкчелек итә. “РСФСР ның халык мәгарифе отличнигы” (1959 ел), “Татарстанның атказанган укытучысы” (1962 ел) дигән мактаулы исемнәргә лаек була. 1970 елда республиканың Мактау Китабына кертелә. Аңа РСФСР Мәгариф министрлыгының Почет грамотасы бирелә.

**Березняк сигезьеллык мәктәбе**

1961 нче елда мәктәп сигезьеллыкка үзгәртелә.Районда төзелә башлаган мәктәпләрдән беренче булып 1961-62 нче уку елында Березняк сигезьеллык мәктәбе үзеннең укучыларын яңа бинада кабул итә. Яңа мәктәпкә Березняк, Камышлы, Аман – Оштарма, Югары Оштарма, Тәмле Чишмә, Сәрдәвеч авылларыннан килеп укыйлар. Березняк сигезьеллык мәктәбе тарихында гаиләләре белән аның үсешенә өлеш керткән шәхесләр дә шактый: Ваһапов Харис Ваһапович һәм Нуриева Резеда Нуриевна, Шәрипова Мөнирә Зариповна һәм Марданов Нәкыйп Абдуллович, Фатыйхов Гариф Фатыйхович һәм Әхмәтҗәнова Нурания Ахуновналар.



**Березняк урта мәктәбе**

1986 нчы ел. Березняк мәктәбе урта мәктәп статусы ала. Директор итеп Арсланов Айдар Азатович билгеләнә. Ул мәктәптә 1998 нче елга кадәр эшли.1998 нче елдан мәктәпне Фахрутдинов Альберт Мингазович җитәкли.

**XXI - гасырда безнең мәктәп**

2004 нче елның көзендә яңа мәктәп бинасының беренче нигез ташы салына. 2006 - 2007 нче уку елын укучыларыбыз яңа бинада каршылый.



2006 нчы елның 3 нче ноябрендә Березняк урта мәктәбенә РСФСРның Халык мәгарифе отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы Ваһапов Харис Ваһапович исеме бирелә.

Мәгариф системасында барган үзгәрешләр безнең мәктәбебезгә дә кагылып узды. 2015 нче елдан төп гомуми белем бирү мәктәбе статусында калдырылды.